ИРТӘНГЕ сәгатьләр авылда бигрәк матур була. Сузып-сузып әтәчләр кычкыруга инде сыерлар да мөгери башлый. Авыл халкы йокыдан уяна. Җәй —киеренке хезмәт чоры. Моны һәркем яхшы белә. Шуңа берәү дә йоклап ятмый. Комбайнчы ярдәмчесе булып йөрүче укучы малайлар да йокыларын бер читкә калдырып, түгәрәк өстәл артына утыралар әнә. Комбайн. Әйе, аңар мәхәббәт миндә дә нәкъ шул малайлар шикелле бала чакта туа башлады. Комбайнчы абыйларның детальләрне алыштыруларын, кирәкле запас частьләрне эретеп ябыштыруларын карап торырга ярата идем. Кирәк чагында ачкычлар биреп торам. Минем күзләрем өметле күренгән күрәсең, «комачаулап йөрисең» дип куып җибәрмәделәр.

Икмәк исе миңа шуңа да кечкенәдән яхшы таныш. Гарәбәдәй сары бөртекләрне йөземә якын китереп, аларга озаклап карап торырга яратам. Никадәрле көч түгәләр аны үстерү өчен игенчеләр. Үсмер егет булгач, комбайн ярдәмчесе булып йөрдем. Кайбер көннәрдә кыр штурвалы артына үзем дә утыргаладым. Бу көннәрдә минем йөземә нинди шатлык, горурлык хисләре иңүен күрсәгез иде сез. Аннан армиягә алдылар. Совет Армиясе сафларында хезмәт иткән чагымда бик аз көннәр генә туган авылымны искә төшермәгәнмендер. Беренче елларда башак шавын төшләремдә ишетеп төшләнеп беттем. Кайтыр вакыт җиткәч тә шулай булды. Сагындыра, бик сагындыра икән ул туган якның басукырлары.

# Таң белән бергә

Мин утырган поезд Татарстанга ашкына. Шатлыктан йөрәк ярсып-ярсып тибә. Димәк, минем бу кулларым исән-сау, үз колхозымда кыр корабларына тагын утырачакмын әле, дип эчтән куанам. 1951 ел иде бу. Тик комбайнга шунда ук утырмадым әле, башта МТС укырга җибәрде. Шул рәвешчә, ничә айлыктыр, хәтерләмим, тракторчылар курсларын тәмамларга туры килде. Беренче мәртәбә комбайнның тулы хуҗасы булып кырга чыгу күңелләрдә әйтеп бетергесез тәэсир калдыра икән. Курка-курка гына тизлекне арттырам, ә үзем минут саен артка күз ташлыйм: комбайн теземнәрне тигез алдырамы. Шулай башланды комбайнда минем хезмәт биографиям. Аннан соң инде тәҗрибәле остаз буларак, күп мәртәбәләр, 40 ел гына, уңышны урып-җыю чорында катнаштым, эш булгач, төрлесе булды: кычкырышкан, ызгышкан, җитешмәгән, үпкәләгән, бер-беребезне аңламаган чаклар. Элек бит без әле аренда алымы белән эшләми идек, шуңа бер-беребез белән бәхәсләшеп бетә идек. Аннан үзеңә беркетелгән участокны ялгыз эшләү дә җиңелгә туры килми. Җимерелгән очракта кыр станында комбайн төзәтеп көннәрне дә үткәргән булгалады. Хәзер гел башкача. Кумәкләшеп кырга чыгабыз, кирәк чагында бер-беребезгә ярдәм итәбез. Эш тә гөрләп бара. Дөрес, уңышны һәр елны игенче югары һәм сыйфатлы итеп алырга тели. Моның өчен уңышка нигез салган вакытта ук ул зур тырышлык куя. Ләкин һәммә нәрсә дә бездән тормый шул. Һава шартларының коры, эссе торуы быел игеннәргә иркенләп үсәргә ирек бирмәде. Ләкин шулай да күңелне төшермибез, булган кадәргесен югалтуларсыз, әрәм-шәрәм итмичә җыеп алырга тырышабыз. Узган елны мин үземнең СК-5 комбайнында урак башланганнан бирле 5000 центнер ашлык суктырып, колхозда беренче урынга чыккан идем. Быел да алдынгылыкны үз кулыма алу өчен көчемне кызганмыйча һәм вакыт белән исәпләшмичә эшлим.

Үзем кебек озак еллар комбайнда эшләүче Минхаҗан Гобәйдуллин һәм Гәрәй Садретдиновлар турында да берничә сүз әйтеп үтәсем килә. Аларның бер генә мәртәбә дә эшләрен сыйфатсыз башкарганнарын хәтерләмим. Сабыр холыклы, тыңлаучан бу кешеләрне коллективта да хөрмәт итәләр. Әнә шундыйлар яшьләрне тәрбияләүдә зур роль уйный да.

Көзгә улым Марат армиядән кайтачак. Комбайнда эшләячәкмен, дип хат язган. Балаларыбызның туган авылларында калырга теләк белдерүләре—безнең өчен чын шатлык ул.

...Тагын таң ата. Без әтәчләр белән бергә торабыз. Кырларга чыгасы бар бит безнең.

**Х. ГАТИН,**
Муса Җәлил исемендәге колхоз комбайнчысы.



Кордашлар Александр Владимирович Глухов һәм Якуб Ибраһимович Рәхмәтуллинны күп нәрсә берләштерә. Һәр икесе яшьтән техникага гашыйк, авыл җирендә төпләнгән кешеләр. Һәр икесе тракторда эшлиләр, бер үк эш—КС-2,1 чапкычы белән борчак чабуда хезмәт куйдылар алар. Аңа кадәр җәмәгать маллары өчен терлек азыгы әзерләүдә эшләделәр, инде хәзер, борчак чабуны тәгәлләгәч тә азык әзерләүчеләр сафына кушылачаклар. Шулай эшләнәсе эш бетеп тормый авыл уңганнары өчен.

Рәсемдә: «Төрнәс» совхозы механизаторлары А. В. Глухов һәм Я. И. Рәхмәтуллин.

## Шәһәребез —туган йортыбыз

# Баштан сыйпамасалар да...

Шәһәр урамыннан узучы йөк машиналарының кузовыннан һәм РМГ кузовыннан сибелеп, түгелеп барган саргылт ак порошокка карап, кешеләр: «Нәрсә бу? Ашламаны шулай ташыйлар ахры?»—диешәләр. Юлга агып барган эз буенча әлеге машиналар агымына каршы юнәлештә юл тотабыз. Юлыбыз «Агропромхимия» берләшмәсенең үлчәүләр башындагы капкасында тәгәлләнә. Менә кайда икән аның чыганагы! Үлчәү янындагы ярдәмче бинада үлчәү ягындагы тәрәзәгә гамьсез генә карангалап ике ханым утыра. Склад мөдирләре Т. Колмөхәммәтова һәм З. Хисмәтуллина икән алар. Санэпидстанциянең баш врачы И. Андаровның: «Йөк төялгән машиналарның нигә өстен капламыйлар?»—дигән соравына каршы алар болай дип җавап бирделәр: «Брезентлары да юк аларның, югалтып бетерәләр. Ә болары—известь оны гына ташыйлар. Капламыйлар, өстеннән тузан булып күтәрелмәсен өчен су гына сибәләр. Ә минераль ашлама ташыганда, әлбәттә, өсләрен каплыйлар.

Көнгә 300—400 тонна йөк озаталар икән берләшмәдән. Бүгенге көндә «ак юл сызып» уза торган машина һәм тракторлар «Игенче» һәм «Большевик» колхозларына известь оны ташыйлар. Һәм шуның күпмесе чын мәгънәсендә җилгә оча икән, беләсе иде.

Бу уңайдан берләшмә начальнигы Р. Һ. Гыймалетдиновның фикере белән кызыксындык. «Дөрес әйтәсез, кузов өстен ябарга тиешләр. Әмма ябылмаган очракта су сибәбез бит», —дип акланды ул. «Каплау өчен япма-брезенты булмаганнарын ник төямичә кире бормыйсыз?»—дигән сорауга да җитәкче уңайсызланып кына җавап бирде. «50—60 шар километр яки аннан да күбрәк юл узып килгән шоферны ничек инде буш килеш борасың? Күпме ягулык-май сарыф итә ул. Вакытын әйткән дә юк. Шуларын уйлыйсың да төятеп озатасың инде. Кире кагарсың —кагуын, аннан соң югарыдагыларга аңлата башласаң, шул аңлашу белән көнең үтәчәк. Безнең дә баштан сыйпамаслар...»—диде җитәкче иптәш.

Әйе шул, барысын да уңайга гына сыйпап, үз агымына гына куеп, мөнәсәбәтләрне бозмый гына яшәүдән дә җайлысы юк, үз мәнфәгатен генә кайгыртып яшәгән кешегә. Моның өчен чамадан тыш тырышлык та, сәләт тә таләп ителми. Ә менә халык мәнфәгатен кайгырту андый җиңел юлдан гына бара алмый шул. Принципиаль булырга да, катылык күрсәтергә дә, хәтта ачуланышырга да туры килә бу очракта. Һәм, әлбәттә, беркем дә баштан сыйпарга да ашкынып тормый. Шуңа күрә дә шәһәр урамнары буйлап, ак юллар сызып, саргылт өермә уйнатып, известь оны төялгән автомобильләр чабыша да. 24 меңләп халык яшәгән ямь-яшел шәһәр уртасыннан бу. Һәм аларда беркемнең дә эше дә, кайгысы да юк.

**И. АНДАРОВ,**
санэпидстанциянең баш врачы.

**Р. ГАФУРОВ,**
Октябрь районының табигатьне саклау буенча баш дәүләт инспекторы.

Рейд бригадасы Мичурин исемендәге һәм «Правда» колхозы басуларында һәм ындыр табакларында да булды.

Соңгылары һәр ике хуҗалыкта да тәртиптә, асфальтланган, чистарту, киптерү агрегатлары тулы куәтенә эшли. Мичурин исемендәге колхозда ашлык чистарту агрегатларында укучы балалар эшли, ә «Правда»да бу эшкә район потребительләр җәмгыятеннән дә тартылганнар. Мичурин исемендәге колхозның орлык склады теләсә кем кереп сокланырлык җыйнаклыкта: ул известьланган, дезинфекцияләнгән, күршеләрендә исә бу эш тәгәлләнеп бетмәгән әле. «Правда» колхозында ЗАВ-20 тирәләрендә шулай ук күпләп ашлык сибелеп ята. Әмма шунысы өметләндерә: ындыр табагы мөдире Л. Д. Романов—үз биләмәләрендә тулы хуҗа, ул һәр эшне оештырып, тәртибен белеп башкара.

Мичурин исемендәге колхозның 150 гектарлы солы кырына юнәләбез. Биредә 8 комбайн ике группага бүленеп эшлиләр. Киҗәкне җилләтеп карыйбыз: бер өемдә күпләп бөртек коела. Димәк, бер комбайн бөртек калдырып суга. Кемнеке? Менә шул баш вату арасында мичуринлыларның уйлап җиткермәве сизелде дә: тиешенчә, аерым алын алып эшләгәндә, брак җибәргән комбайнчыны шунда ук ачыкларга мөмкин булыр иде. Әмма иң күзгә ташланган, гафу ителмәслек кимчелек алда икән әле: солы теземнәрен суктырганнан соң да буе-буе белән киселмәгән ашлык җирдә ятып кала. Бу нәрсә?

—Бу Василий Алексеев участогы инде. ЖРБ белән эшләде ул,—дип аңлатты баш агроном Н. Т. Евдокимов. Әмма ул брак бит 2—3 рәттә генә түгел, ничәмә-ничә метрга сузылган участокта, һәм шуны белгечләр шулай тиеш дип кабул иткәннәр күрәсең!

Суктыруда эшләүче комбайнчыларга бу ошамый, әлбәттә.

—Өч көн инде бер комбайныбыз тик тора. Контрпривод валы юк,—ди комбайнчы К. Ф. Никифоров. Карый торгач, аның үз комбайнында да җайлыйсы нәрсә табылды: барабан капкачы тыгызлап ябылмаган.

Икенче бер комбайн суктырып үткән ашлыкның башагында бөртек кала. Бу Аркадий Яргуновныкы икән. Туктатып карасалар, сәбәбе дә шунда ук ачыкланды: барабан белән барабан асты арасы зур икән. Боларның һәммәсе—иң элек комбайнчылар, хуҗалык белгечләре карарга тиешле нәрсәләр, югыйсә. Сабан бодаен теземнәргә салучы Александр Бочкарев һәм Вячеслав Яргунов комбайннарында да карап җиткермәгән нәрсәләр табылды: аларның һәр икесендә пычаклар дөрес йөрми: пычак белән кисүгә каршы (противорежущий) сегмент аралары артык киң, пычак үзәккә дә килеп җитми. Бу шулай ук уру сыйфатына суга. Бу участокта күзгә ташланган нәрсә— теземнәргә салынган борылыш полосасы суктырылмаган, комбайннар шуның аркылы йөриләр. Ә «Правда» колхозында арендатор Н. Алексашкинның солы басуында без нәкъ шуның киресен күреп шатландык: борылыш полосасы алдан суктырылган, камыл тигез калдырып урылган, теземнәр дә тигез яткан. Комбайнчылар группа ысулы белән эшлиләр. Сүз уңаеннан, 160 гектарлы арыш басуында эшләүче комбайнчыларга да тел-теш тидерерлек түгел. Әмма кыр артык чүпле, аннан кайткан ашлыкны кичектермичә чистарту чарасын күрергә кирәк булачак.

Урак дәвам итә. Көннәрнең әйбәт торуы игенчегә тулы куәтенә эшләргә мөмкинлек бирә. Шунда ук эшнең сыйфатын да икенче планга куймыйсы иде. Рейд бригадасы әлегә аңа һәр җирдә дә бер үк дәрәҗәдә игътибар җиткерелмәвен күреп, игенчеләрне кабат шул хакта искәртүне кирәк тапты.

**Н. МУСИН,**
район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе баш агрономы.

**Р. САТДАРОВ,**
«Гостехнадзор» инспекциясе начальнигы.

**С. ХӘЙРУЛЛИНА,**
үз корреспондентыбыз.

